КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 6 апрель г.Казань № 226

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Болгар» шәһәрлеге – Болгар дәүләте башкаласы» федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен билгеләү турында» 2014 ел, 20 июнь, 429 нчы карары белән расланган «Болгар» шәһәрлеге – Болгар дәүләте башкаласы» федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясеннән файдалану режимына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Болгар» шәһәрлеге – Болгар дәүләте башкаласы» федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен билгеләү турында» 2014 ел, 20 июнь, 429 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 19 март, 149 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Болгар» шәһәрлеге – Болгар дәүләте башкаласы» федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясеннән файдалану режимына, егерме өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«мәдәни мирас объектларында «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә мәгълүмати язмалар һәм билгеләр урнаштыру.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин